ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Исемлеккә кертү турындагы гаризага ятим бала паспортының яисә аның шәхесен таныклый торган башка документының күчермәсе, законлы вәкиленең шәхесен һәм аның вәкаләтләрен таныклый торган документ йә ятим баланың тулысынча хокукка сәләтле (эмансипацияләнгән) булуын таныклый торган документ, шулай ук ятим бала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала статусын раслый торган документлар, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган орган тарафыннан ятим баланың Россия Федерациясе территориясендә милек хокукында торак урыны булу-булмавы турында бирелгән белешмә, шулай ук ятим баланың гариза бирү вакытына яшәү урыны йә булу урыны буенча теркәлүен раслый торган документ кушымта буларак бирелә.»;

б) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә кертелгән ятим балага кагылышлы документларны тапшырганда өстәмә рәвештә түбәндәге документлар кушымта буларак бирелә:

1) ятим бала моңа кадәр билән тора торган торак урынына хокук бирүче документның күчермәсе;

2) күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган орган тарафыннан ятим бала моңа кадәр билән тора торган торак урынында яшәүче барлык гражданнарга Россия Федерациясе территориясендә милек хокукында торак урыннары булу-булмау турында бирелгән белешмә;

3) ятим бала гаиләсенең (булган очракта) составы турындагы документларның күчермәләре;

4) ятим бала билән тора торган торак урынында яшәү мөмкинлекләре булмауның Федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән шартларын раслаучы документлар, моңа әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән шартлар керми. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән шартларны раслау өчен кирәкле документлар вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеге кысаларында соратып алына.»;

г) 6 өлештә «4 һәм 5 өлешләрендә» сүзләрен «3 һәм 5 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 өлештә «әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә керә торган ятим балаларның моңа кадәр билән тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булу йә булмау турында бәяләмә бирә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 12 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Ятим балаларны исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту хакында карарга законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәргә:

«$2^1$ статья. **Ятим балаларның моңа кадәр билән тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булмавын тану тәртибе**

1. Вәкаләтле орган ятим балаларның моңа кадәр билән тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булмавы шартларын билгеләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) төзи. Комиссиягә вәкаләтле орган җитәкчесе җитәкчелек итә.

2. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы вәкаләтле орган җитәкчесе карары белән раслана.

3. Вәкаләтле орган әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә кертелгән ятим балага кагылышлы документларны алган очракта, комиссия, документларны тапшыру вазыйфасы йөкләнгән гариза бирүче тарафыннан документлар тапшырылганнан соң 14 көннән дә соңга калмыйча, әлеге

органга ятим балаларның моңа кадәр билән тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләренең булуы йә булмавы турында бәяләмә бирә.

4. Ятим балаларның моңа кадәр билән тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлекләре булуы йә булмавы турында бәяләмәгә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 елның 18 декабре
№ 124-ТРЗ